# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан государственными полномочиями Республики Татарстан по осуществлению государственного контроля и надзора в области долевого строительства многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 мая 2017 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 27 декабря 2007 года № 66-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан государственными полномочиями Республики Татарстан по осуществлению государственного контроля и надзора в области долевого строительства многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 12 (II часть); 2010, № 5 (I часть), № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 8 (I часть); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7) следующие изменения:

1) в наименовании слова «контроля и надзора» заменить словами «контроля (надзора)», дополнить словами «, а также за деятельностью жилищно-строительных кооперативов, связанной со строительством многоквартирных домов»;

2) преамбулу после слов «Федеральным законом от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации»,» дополнить словами «Жилищным кодексом Российской Федерации,», слова «контроля и надзора» заменить словами «контроля (надзора)», дополнить словами «, а также за деятельностью жилищно-строительных кооперативов, связанной со строительством многоквартирных домов»;

3) статью 1 изложить в следующей редакции:

«Статья 1. **Государственные полномочия, которыми наделяются органы местного самоуправления**

Органы местного самоуправления наделяются следующими государственными полномочиями Республики Татарстан по осуществлению государственного контроля (надзора) в области долевого строительства многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, а также за деятельностью жилищно-строительных кооперативов, связанной со строительством многоквартирных домов (далее – государственные полномочия):

осуществление контроля за целевым использованием застройщиком денежных средств, уплачиваемых участниками долевого строительства по договору, для строительства (создания) многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости в соответствии с Федеральным законом от 30 декабря 2004 года № 214-ФЗ «Об участии в долевом строительстве многоквартирных домов и иных объектов недвижимости и о внесении изменений в некоторые законодательные акты Российской Федерации» (далее – Федеральный закон);

осуществление контроля за соблюдением застройщиком установленных частью 2 статьи 3 Федерального закона требований к застройщику;

осуществление контроля за соблюдением застройщиком установленных статьей $3^1$ Федерального закона требований к раскрытию и размещению им информации;

осуществление контроля за соблюдением застройщиком примерных графиков реализации проектов строительства;

осуществление контроля за соблюдением застройщиком установленных частью $1^2$ статьи 18 Федерального закона требований к ведению учета денежных средств, уплачиваемых участниками долевого строительства;

выдача заключения о соответствии застройщика и проектной декларации требованиям, установленным частью 2 статьи 3, статьями 20 и 21 Федерального закона, либо мотивированного отказа в выдаче такого заключения;

получение от застройщика информации о физическом лице, которое в конечном счете прямо или косвенно (через третьих лиц) владеет (имеет в капитале преобладающее участие более чем 25 процентов) корпоративным юридическим лицом – застройщиком;

получение от застройщика информации о лицах, осуществляющих работы, поставки товаров и (или) предоставляющих услуги по проведению инженерных изысканий, архитектурно-строительного проектирования и строительства, с указанием полного наименования юридического лица или фамилии, имени, отчества (если имеется) индивидуального предпринимателя, адреса (места нахождения), а также о видах таких товаров, работ, услуг и информации о наличии у этих лиц соответствующих допусков (лицензий) к осуществлению указанных видов работ, поставок товаров и предоставлению услуг, если законодательством Российской Федерации предусмотрено требование о наличии указанных допусков (лицензий), в порядке и в сроки, которые установлены федеральным органом исполнительной

власти, уполномоченным на осуществление государственного регулирования в области долевого строительства многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости (далее – уполномоченный федеральный орган исполнительной власти);

получение от федерального органа исполнительной власти, уполномоченного на осуществление функций по формированию официальной статистической информации, документов и информации, необходимых для осуществления контроля за деятельностью застройщиков, связанной с привлечением денежных средств участников долевого строительства для строительства (создания) многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, а также документов и информации, необходимых для осуществления контроля за деятельностью жилищно-строительного кооператива, связанной с привлечением средств членов кооператива для строительства многоквартирного дома;

получение в порядке межведомственного информационного взаимодействия от федерального органа исполнительной власти, осуществляющего функции по контролю и надзору за соблюдением законодательства о налогах и сборах, выписки из единого государственного реестра юридических лиц (сведений, содержащихся в ней), документов и информации, необходимых для осуществления контроля за соблюдением застройщиком требований, установленных пунктом 7 части 2 статьи 3 Федерального закона, а также документов и информации, необходимых для осуществления контроля за деятельностью жилищно-строительных кооперативов, связанной с привлечением денежных средств граждан для строительства жилищно-строительными кооперативами многоквартирного дома;

получение в порядке межведомственного информационного взаимодействия от федерального органа исполнительной власти, осуществляющего функции по выработке и реализации государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере внутренних дел, документов и информации, необходимых для осуществления контроля за соблюдением застройщиком требований, установленных пунктом 8 части 2 статьи 3 Федерального закона, а также документов и информации, необходимых для осуществления контроля за соблюдением требований, установленных пунктом 1 статьи $116^1$ Жилищного кодекса Российской Федерации;

получение от федерального органа исполнительной власти, уполномоченного на осуществление государственного кадастрового учета, государственной регистрации прав, ведение Единого государственного реестра недвижимости и предоставление сведений, содержащихся в Едином государственном реестре недвижимости (далее – орган регистрации прав), документов и информации, необходимых для осуществления контроля за деятельностью застройщиков, связанной с привлечением денежных средств участников долевого строительства для строительства (создания) многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, а также за деятельностью жилищно-строительного кооператива, связанной с привлечением денежных средств граждан для строительства жилищно-строительным кооперативом многоквартирного дома;

получение от лиц, привлекающих денежные средства граждан для строительства, в определенный статьей 11 Федерального закона от 26 декабря

2008 года № 294-ФЗ «О защите прав юридических лиц и индивидуальных предпринимателей при осуществлении государственного контроля (надзора) и муниципального контроля» срок сведений и (или) документов, которые необходимы для осуществления государственного контроля (надзора) в области долевого строительства многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости и перечень которых устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан;

получение от застройщиков ежеквартальной отчетности об осуществлении деятельности, связанной с привлечением денежных средств участников долевого строительства для строительства (создания) многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, в том числе об исполнении застройщиком примерных графиков реализации проектов строительства, своих обязательств по договорам, а также промежуточной и годовой бухгалтерской (финансовой) отчетности, составленной в соответствии с требованиями законодательства Российской Федерации;

получение ежеквартальной отчетности от жилищно-строительного кооператива об осуществлении деятельности жилищно-строительного кооператива, связанной с привлечением денежных средств граждан для строительства жилищно-строительным кооперативом многоквартирного дома, в том числе об исполнении таким кооперативом своих обязательств перед членами кооператива и иными лицами, по формам и в порядке, которые установлены уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти, а также промежуточной и годовой бухгалтерской (финансовой) отчетности, составленной в соответствии с требованиями законодательства Российской Федерации;

осуществление контроля за деятельностью застройщиков, связанной с привлечением денежных средств участников долевого строительства для строительства (создания) многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости;

осуществление контроля за соблюдением требований Федерального закона, в том числе направление запросов в Центральный банк Российской Федерации о предоставлении информации о соответствии банка, с которым застройщиком заключен договор поручительства, или страховой организации, с которой застройщиком заключен договор страхования, требованиям Федерального закона, а также рассмотрение жалоб граждан и юридических лиц, связанных с нарушением Федерального закона;

направление лицам, привлекающим денежные средства граждан для строительства многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, предписаний об устранении нарушений требований Федерального закона, а также иных требований по вопросам привлечения денежных средств граждан для строительства (создания) многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, установленных нормативными правовыми актами Президента Российской Федерации, нормативными правовыми актами Правительства Российской Федерации, нормативными правовыми актами уполномоченного федерального органа исполнительной власти, и установление сроков устранения таких нарушений;

размещение на своем официальном сайте в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» информации о проведенных проверках деятельности застройщика, жилищно-строительного кооператива, за исключением сведений, доступ к которым ограничен законодательством Российской Федерации, а также размещение сведений о вступивших в законную силу постановлениях о привлечении застройщика, его должностных лиц к административной ответственности за нарушение требований Федерального закона, сведений о привлечении жилищно-строительного кооператива к административной ответственности за нарушение требований Жилищного кодекса Российской Федерации и иных требований, установленных законодательством;

принятие мер, необходимых для привлечения лиц, привлекающих денежные средства граждан для строительства (их должностных лиц), жилищно-строительных кооперативов (их должностных лиц) к ответственности, установленной Федеральным законом и законодательством Российской Федерации;

обращение в суд с заявлениями в защиту прав и законных интересов участников долевого строительства, а также предусмотренных главой 11 Жилищного кодекса Российской Федерации прав и законных интересов членов жилищно-строительного кооператива, которые своими средствами участвуют в строительстве многоквартирного дома, в случае нарушения таких прав и интересов;

направление в правоохранительные органы материалов, связанных с нарушениями обязательных требований, для решения вопросов о возбуждении уголовных дел по признакам преступлений;

признание в соответствии с установленными уполномоченным федеральным органом исполнительной власти критериями граждан, чьи денежные средства привлечены для строительства многоквартирных домов и чьи права нарушены, пострадавшими и ведение реестра таких граждан;

обращение в арбитражный суд с заявлением о приостановлении на определенный срок осуществления застройщиком деятельности, связанной с привлечением денежных средств участников долевого строительства для строительства (создания) многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, либо с заявлением о ликвидации лица, привлекающего денежные средства граждан для строительства, в случаях, установленных частями 15 и 16 статьи 23 Федерального закона;

осуществление контроля (надзора) за привлечением денежных средств граждан для строительства жилищно-строительными кооперативами многоквартирных домов в соответствии с федеральными законами, регулирующими деятельность таких кооперативов, с учетом положений Федерального закона о контроле за деятельностью застройщиков, связанной с привлечением денежных средств участников долевого строительства для строительства (создания) многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости;

осуществление контроля за соблюдением жилищно-строительным кооперативом установленных частью 1 статьи $123^1$ Жилищного кодекса Российской Федерации требований к размещению им информации и документов;

осуществление в соответствии с частью 4 статьи $123^2$ Жилищного кодекса Российской Федерации проверки деятельности жилищно-строительного

кооператива, связанной с привлечением средств членов кооператива для строительства многоквартирного дома;

получение от жилищно-строительного кооператива и иных лиц, с которыми такой кооператив заключил договоры, связанные со строительством многоквартирного дома, в определенный статьей 11 Федерального закона от 26 декабря 2008 года № 294-ФЗ «О защите прав юридических лиц и индивидуальных предпринимателей при осуществлении государственного контроля (надзора) и муниципального контроля» срок документов и информации, которые необходимы для осуществления государственного контроля (надзора) за деятельностью жилищно-строительного кооператива, связанной с привлечением денежных средств граждан для строительства жилищно-строительным кооперативом многоквартирного дома, и перечень которых устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан;

требование от органов управления жилищно-строительного кооператива устранения выявленных нарушений;

рассмотрение жалоб граждан и юридических лиц, связанных с нарушением жилищно-строительным кооперативом требований части 3 статьи 110 Жилищного кодекса Российской Федерации, за исключением последующего содержания многоквартирного дома, и статьи $123^1$ Жилищного кодекса Российской Федерации;

направление в жилищно-строительный кооператив обязательных для исполнения предписаний об устранении нарушений требований части 3 статьи 110 Жилищного кодекса Российской Федерации, за исключением последующего содержания многоквартирного дома, и статьи $123^1$ Жилищного кодекса Российской Федерации и установление сроков устранения таких нарушений;

вынесение предписания о приостановлении деятельности жилищно-строительного кооператива по привлечению новых членов кооператива в случае неисполнения жилищно-строительным кооперативом в установленный срок предписания об устранении выявленных нарушений, а также в случае, если эти нарушения создают реальную угрозу правам и законным интересам членов жилищно-строительного кооператива, до устранения жилищно-строительным кооперативом соответствующих нарушений, обращение в суд с требованием о ликвидации жилищно-строительного кооператива в случае неисполнения предписаний этим кооперативом;

получение сведений, содержащихся в реестре членов жилищно-строительного кооператива, а также иной информации, предусмотренной статьей $123^1$ Жилищного кодекса Российской Федерации, из государственной информационной системы жилищно-коммунального хозяйства.»;

4) в статье 6:

а) пункт 1 части 1 дополнить словами «, а также документы и информацию, необходимые для осуществления контроля за деятельностью жилищно-строительного кооператива, связанной с привлечением средств членов кооператива для строительства многоквартирного дома (в том числе документы, связанные со строительством многоквартирного дома)»;

б) в пункте $5^1$ части 2 слова «абзацем девятым» заменить словами «абзацем двадцать пятым», слова «органы, осуществляющие государственную регистрацию прав на недвижимое имущество и сделок с ним,» заменить словами «орган регистрации прав»;

5) в приложении слова

«Приложение<br>к Закону Республики Татарстан<br>«О наделении органов местного<br>самоуправления муниципальных районов<br>и городских округов Республики Татарстан<br>государственными полномочиями<br>Республики Татарстан по осуществлению<br>государственного контроля и надзора<br>в области долевого строительства<br>многоквартирных домов и (или)<br>иных объектов недвижимости»

заменить словами

«Приложение<br>к Закону Республики Татарстан<br>«О наделении органов местного<br>самоуправления муниципальных районов<br>и городских округов Республики Татарстан<br>государственными полномочиями<br>Республики Татарстан по осуществлению<br>государственного контроля (надзора)<br>в области долевого строительства<br>многоквартирных домов и (или)<br>иных объектов недвижимости, а также<br>за деятельностью жилищно-строительных<br>кооперативов, связанной со строительством<br>многоквартирных домов».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент<br>Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль<br>26 мая 2017 года<br>№ 33-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «өлкәсендә» сүзеннән соң «, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген» сүзләрен өстәргә, «дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген» сүзләрен «дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне)» сүзләренә алмаштырырга;

2) преамбулада «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Торак кодексы» сүзләрен, «өлкәсендә» сүзеннән соң «, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген» сүзләрен өстәргә, «дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген» сүзләрен «дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә:

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар шартнамә буенча түли торган акчаларның төзүче тарафыннан максатчан кулланылуын тикшереп тору;

төзүчегә карата Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләрнең аның тарафыннан үтәлүен тикшереп тору;

төзүче тарафыннан мәгълүматны ачып бирүгә һәм урнаштыруга карата Федераль законның $3^1$ статьясында билгеләнгән таләпләрнең аның тарафыннан үтәлүен тикшереп тору;

төзүченең төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларын үтәвен тикшереп тору;

өлешле төзүдә катнашучылар түли торган акчаларның исәбен алып баруга карата Федераль законның 18 статьясындагы $1^2$ өлешендә билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлүен тикшереп тору;

төзүченең һәм проект декларациясенең Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү йә мондый бәяләмә бирүдән дәлилләп баш тарту;

төзүчедән ахыр чиктә турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аркылы) корпоратив юридик затка – төзүчегә хуҗа булган (капиталда өстенлекле катнашуы 25 проценттан артык булган) физик зат турында мәгълүмат алу;

төзүчедән федераль башкарма хакимиятнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы) билгеләгән тәртиптә һәм срокларда, юридик затның тулы исемен яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда), адресын (урнашкан урынын) күрсәтеп, эшләрне башкаручы, товарлар ташучы һәм (яисә) инженер эзләнүләре башкару, архитектура-төзелеш проектлавы һәм төзелеш хезмәтләрен күрсәтүче затлар, шулай ук мондый товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең төрләре турында һәм, Россия Федерациясе законнарында күрсәтелгән эш төрләрен башкаруга, товарлар ташуга һәм хезмәтләр күрсәтүгә тиешле рөхсәтләр (лицензияләр) булу таләбе каралган очракта, бу затларда күрсәтелгән рөхсәтләр (лицензияләр) булу хакында мәгълүмат алу;

федераль башкарма хакимиятнең рәсми статистик мәгълүматны формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органыннан төзүчеләрнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат, шулай ук торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат алу;

федераль башкарма хакимиятнең салымнар һәм җыемнар турындагы законнар үтәлешен тикшереп тору һәм күзәтчелек итү функцияләрен гамәлгә ашыручы органыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек тәртибендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (андагы белешмәләр), Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 7 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлүен тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының алар тарафыннан күпфатирлы йортны төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат алу;

федераль башкарма хакимиятнең эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы органыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек тәртибендә Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 8 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлүен тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының $116^1$ статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат алу;

федераль башкарма хакимиятнең дәүләт кадастр исәбенә алуны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне бирүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органыннан (алга таба – хокукларны теркәү органы) төзүчеләрнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген, шулай ук торак-төзелеш кооперативының аның тарафыннан күпфатирлы йортны төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат алу;

төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затлардан «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән вакытта күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган белешмәләр һәм (яисә) документлар алу;

төзүчеләрдән күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын

җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру, шул исәптән төзүченең төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларын, шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен үтәве турында квартал саен хисаплылык, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын алу;

торак-төзелеш кооперативыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән рәвешләрдә һәм тәртиптә торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортны төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативының эшчәнлеген гамәлгә ашыру, шул исәптән мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм башка затлар каршындагы үз йөкләмәләрен үтәве турында квартал саен хисаплылык алу;

төзүчеләрнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору;

Федераль закон таләпләренең үтәлешен тикшереп тору, шул исәптән Россия Федерациясе Үзәк банкына төзүче белән поручительлек шартнамәсе төзегән банкның яисә төзүче белән иминләштерү шартнамәсе төзегән иминият оешмасының Федераль закон таләпләренә туры килүләре турында мәгълүмат бирүне сорап гарызнамәләр җибәрү, шулай ук Федераль законны бозуга карата гражданнарның һәм юридик затларның шикаятьләрен карау;

күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затларга Федераль закон таләпләрен, шулай ук күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка таләпләрне бозуны бетерү турында күрсәтмәләр җибәрү һәм мондый хокук бозуларны бетерү срокларын билгеләү;

үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында төзүченең, торак-төзелеш кооперативының эшчәнлегенә уздырылган тикшерүләр турында мәгълүмат, файдалана алуы Россия Федерациясе законнары белән чикләнгән белешмәләрдән тыш, урнаштыру, шулай ук төзүчене, аның вазыйфаи затларын Федераль закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту хакында үз көченә кергән карарлар турында белешмәләр, торак-төзелеш кооперативын Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен һәм законнарда билгеләнгән башка таләпләрне бозган өчен административ җаваплылыкка тарту хакында белешмәләр урнаштыру;

төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затларны (аларның вазыйфаи затларын), торак-төзелеш кооперативларын (аларның вазыйфаи затларын) Федераль законда һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чаралар күрү;

өлешле төзүдә катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук үз акчалары белән күпфатирлы йортны төзүдә катнашучы торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының Россия Федерациясе Торак кодексының 11 бүлегендә каралган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап, мондый хокукларны һәм законлы мәнфәгатьләрне бозган очракта, гаризалар белән судка мөрәҗәгать итү;

хокук саклау органнарына җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату мәсьәләләрен хәл итү өчен мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материаллар җибәрү;

вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән критерийлар нигезендә акчалары күпфатирлы йортларны төзүгә җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күргәннәр дип тану һәм мондый гражданнарның реестрын алып бару;

Федераль законның 23 статьясындагы 15 һәм 16 өлешләрендә билгеләнгән очракларда күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекнең төзүче тарафыннан гамәлгә ашырылуын билгеле бер вакытка туктатып тору турындагы гариза белән йә төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затны ликвидацияләү хакындагы гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итү;

төзүчеләрнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору турындагы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлеген җайга сала торган федераль законнар нигезендә мондый кооперативлар тарафыннан күпфатирлы йортларны төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүне тикшереп тору;

торак-төзелеш кооперативы тарафыннан мәгълүматны һәм документларны урнаштыруга карата Россия Федерациясе Торак кодексының $123^1$ статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән таләпләрнең аның тарафыннан үтәлүен тикшереп тору;

Россия Федерациясе Торак кодексының $123^2$ статьясындагы 4 өлеше нигезендә торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшерү;

торак-төзелеш кооперативыннан һәм мондый кооператив белән күпфатирлы йортны төзүгә бәйле шартнамәләр төзегән башка затлардан «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән вакытта торак-төзелеш кооперативының аның тарафыннан күпфатирлы йортны төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган документлар һәм мәгълүмат алу;

торак-төзелеш кооперативының идарә итү органнарыннан ачыкланган хокук бозуларны бетерүне таләп итү;

торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеше, күпфатирлы йортны аннан соңгы карап торудан тыш, һәм Россия Федерациясе Торак кодексының $123^1$ статьясы таләпләрен бозуга карата гражданнарның һәм юридик затларның шикаятьләрен карау;

торак-төзелеш кооперативына Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеше, күпфатирлы йортны аннан соңгы карап торудан тыш, һәм Россия Федерациясе Торак кодексының $123^1$ статьясы таләпләрен бозуны бетерү турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмәләр җибәрү һәм мондый хокук бозуларны бетерү срокларын билгеләү;

торак-төзелеш кооперативы билгеләнгән вакытта ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәмәгән очракта, шулай ук бу хокук бозулар торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә реаль куркыныч тудырган очракта, торак-төзелеш кооперативының кооперативка яңа әгъзалар җәлеп итү эшчәнлеген аның тарафыннан тиешле хокук бозуларны бетергәнчегә кадәр туктатып тору хакында күрсәтмә чыгару, шушы кооператив күрсәтмәләрне үтәмәгән очракта торак-төзелеш кооперативын ликвидацияләү таләбе белән судка мөрәҗәгать итү;

торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасыннан торак-төзелеш кооперативы әгъзалары реестрындагы белешмәләрне, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының $123^1$ статьясында каралган башка мәгълүматны алу.»;

4) 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «мәгълүматны» сүзеннән соң «, шулай ук торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны (шул исәптән күпфатирлы йортны төзүгә бәйле документларны)» сүзләрен өстәргә;

б) $5^1$ пунктның 2 өлешендә «тугызынчы абзацында» сүзләрен «егерме бишенче абзацында» сүзләренә, «күчемсез мөлкәткә һәм алар белән алыш-биреш килешүләренә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органнарга» сүзләрен «хокукларны теркәү органына» сүзләренә алмаштырырга;

5) кушымтада

«Татарстан Республикасы муниципаль<br>районнары һәм шәһәр округлары җирле<br>үзидарә органнарына күпфатирлы<br>йортларны һәм (яисә) күчемсез<br>мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле<br>төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын<br>һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча<br>Татарстан Республикасы дәүләт<br>вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан<br>Республикасы Законына кушымта»

сүзләрен

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта»

сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 26 май
№ 33-ТРЗ